ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2021 Казан ш. № 469-136/кс-2021

«Мамадыш су каналы» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 07.12.2018 №10-137/кс карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, эчә торган суга, су агызуга 2022-2023 елларга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай керемenә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Мамадыш су каналы» акционерлык җәмгыяте өчен 2019-2023 елларга эчә торган суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләү турында» 07.12.2018 №10-137/кс карарының (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 27.11.2019 №10-121/кс, 11.11.2020 №184-41/кс-2020 карарлары керткән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бирергә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 07.12.2018 № 10-137/кс карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 08.12.2021 № 469-136/кс-2021 карары редакциясендә) 1 нче кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Мамадыш су каналы» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2019-2023 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Ташландык су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | Мамадыш муниципаль районы | | | |
| 1 | «Мамадыш су каналы» акционерлык җәмгыяте | | | |
| 1.1 | халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 40,06 | 32,62 |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 41,63 | 33,46 |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 41,63 | 33,18 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 42,32 | 33,18 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 42,32 | 33,18 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 43,98 | 34,18 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 43,98 | 34,18 |
| | | 01.07.2022 башлап | 46,03 | 36,19 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 31.12.2022 кадәр | | |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 45,73 | 34,90 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 45,73 | 34,90 |
| 1.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 33,38 | 27,18 |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 34,69 | 27,88 |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 34,69 | 27,65 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 35,27 | 27,65 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 35,27 | 27,65 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 36,65 | 28,48 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 36,65 | 28,48 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 38,36 | 30,16 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 38,11 | 29,08 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 38,11 | 29,08 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге